**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 февраль № 94

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген бәяләү критерийлары турында» 2010 ел, 15 июнь, 476 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген бәяләү критерийлары турында» 2010 ел, 15 июнь, 476 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 17 февраль, 113 нче; 2012 ел, 11 февраль, 102 нче; 2012 ел, 19 июнь, 525 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийлары турында»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийларын (алга таба – дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийлары);

мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийларын хисаплап чыгару методикасын;

Автоном учреждениеләрнең икътисадый эшчәнлеге аудиты бертип методикасын (алга таба – Бертип методика).»;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

ел саен, 1 декабрьгә кадәр, чираттагы финанс елына һәр дәүләт оешмасы буенча дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийларының мәгънәләрен раслауны тәэмин итәргә;

һәр дәүләт оешмасы буенча дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийлары мәгънәләрен формалаштырганда билгеләнгән тәртиптә расланган норматив мәгънәләргә ирешүне тәэмин итәргә.»;

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба - «ТР ИhСТҮ» дәүләт бюджет учреждениесе) фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартларына, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмалары (алга таба – дәүләт оешмалары) эшчәнлеге бәясенә туры килү-килмәүне тикшерү буенча тикшерүдә тоту чараларын үткәргәндә Бертип методикадан файдаланырга.»;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Бу карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән министрлыкларга ел саен, 1 майга кадәр, дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийлары мәгънәләренә ирешү турындагы мәгълүматны «ТР ИhСТҮ» дәүләт бюджет учреждениесенә керүне тәкъдим итәргә.

«ТР ИhСТҮ» дәүләт бюджет учреждениесенә ел саен, 25 майга кадәр, дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийлары мәгънәләренә ирешү турында мәгълүмат җыюны, системалаштыруны һәм эшкәртүне тәэмин итәргә.»;

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче муниципаль оешмалар эшчәнлеген бәяләү өчен дәүләт

оешмалары эшчәнлеген бәяләү буенча бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән критерийлардан һәм Бертип методикадан файдалануны;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары белән расланган тәртиптә муниципаль оешмалар эшчәнлеген бәяләү критерийлары мәгънәләренә ирешү турында мәгълүмат җыюны, аны системалаштыруны һәм эшкәртүне тәэмин итәүне.»;

әлеге карар белән расланган мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген бәяләү критерийларында:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийлары»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «1. Дәүләт оешмаларының төп эшчәнлеге критерийлары | |
|---|---|
| Дәүләт йөкләмәсен үтәү күләме | процент |
| Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү | агрегирланган индикатор |
| Дәүләт йөкләмәсе составында билгеләнгән күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты күрсәткечләренең план мәгънәләренә ирешү | процент»; |

2 нче пункт исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге критерийлары»;

2 нче пунктның 2.1 – 2.5 нче пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.1. | Дәүләт йөкләмәсен финанслау күләменә карата керем китерә торган эшчәнлектән керемнәр күләме мөнәсәбәте | процент |
| 2.2. | Татарстан Республикасында уртача эш хакына дәүләт оешмасы хезмәткәрләренең уртача эш хакы мөнәсәбәте | процент |
| 2.3. | Татарстан Республикасы икътисадының тиешле өлкәсендә эшләүче дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең уртача эш хакына карата дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең төп төркемнәре буенча уртача эш хакы мөнәсәбәте | процент |
| 2.4. | Үткән елның шундый ук чорына карата дәүләт оешмасының дебиторлык бурычлары үзгәрү | процент |
| 2.5. | Үткән елның шундый ук чорына карата дәүләт оешмасының кредиторлык бурычлары үзгәрү | сум»; |

2 нче пунктның 2.7 нче пунктчасын һәм таблицага сылтаманы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.7. | Норматив кыйммәткә карата дәүләт оешмасы мөлкәтенең 1 кв.метрын карап тотуның факттагы кыйммәте мөнәсәбәте | процент |
| ________________<br>*Сәламәтлек саклау өлкәсендә хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларыннан тыш»; | | |

3 нче пункт исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Мәгариф өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары»;

3 нче пунктның 3.1 нче пунктчасындагы «чагыштырмасы» сүзен «мөнәсәбәте» сүзенә алыштырырга;

4 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

5 нче пунктның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары»;

5 нче пунктның 5.1 – 5.2 нче пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «5.1. | Дәүләт оешмасы тарафыннан күрсәтелүче бер хезмәткәргә туры килә торган дәүләт хезмәте күләме | койка-көн |
| 5.2. | Койкалардан файдалануның уртача еллык күрсәткече | койка-көн»; |

6 нчы пункт исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары»;

6 нчы пунктның 6.1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «6.1. | Бер хезмәткәргә исәпләгәндә дәүләт оешмасы тарафыннан хезмәт күрсәтелгән кешеләр (хезмәт күрсәтүләр) саны | кеше (хезмәт күрсәтүләр)»; |

7 нче пункт исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Яшьләр сәясәте өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары»;

7 нче пунктның 7.2 нче пунктчасындагы «чагыштырмасы» сүзен «мөнәсәбәте» сүзенә алыштырырга;

7 нче пунктның 7.3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «7.3. | Дәүләт физкультура-спорт оешмасында бер тренер-укытучыга (тренерга) туры килә торган шөгыльләнүчеләр саны | кеше»; |

8 нче пунктның 8.1 нче пунктчасындагы «чагыштырмасы» сүзен «мөнәсәбәте» сүзенә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген бәяләү критерийларын хисаплап чыгару методикасында:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийларын хисаплап чыгару методикасы»;

текст буенча тиешле килешләрдәге «дәүләт учреждениеләре» сүзләрен тиешле килешләрдәге «дәүләт оешмалары» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу Методика мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмалары (алга таба – дәүләт оешмалары) эшчәнлеген бәяләү критерийларын хисаплар чыгару тәртибен һәм авырлык коэффициентларын билгели.»;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү өчен башлангыч мәгълүмат сыйфатында дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәләрендә, дәүләт оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарында, дәүләт оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге турындагы хисапларында, мәгълүматларда, статистика мәгълүматларында булган мәгълүматта һәм, Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары мәгълүматларын исәпкә алып, ведомстволар хисаплылыгындагы мәгълүмат файдаланыла.»;

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсе (алга таба – дәүләт йөкләмәсе) кысаларында дәүләт хезмәтләре күрсәтүче (эшләр башкаручы) дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү өчен дәүләт оешмаларының төп эшчәнлеге критерийлары, дәүләт оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге критерийлары, дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары билгеләнә.»;

2 бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийларын хисаплап чыгару тәртибе»;

2.1 нче пунктның 2.1.1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.1. «Дәүләт йөкләмәсе күләмен үтәү» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E = \frac{\sum_{i=1}^{n}\sum_{j=1}^{m} F_{ij} \times NF_{ij}}{\sum_{i=1}^{n}\sum_{j=1}^{m} N_{ij} \times NF_{ij}} \times 100\%,$$

монда:

E – хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсе күләмен үтәү күрсәткече;

i – дәүләт хезмәте күрсәтү (эше) номеры;

n – дәүләт хезмәтләре күрсәтү (эшләре) саны;

j – дәүләт хезмәте күрсәтү (эше) күләме күрсәткече;

m – дәүләт хезмәте күрсәтү (эше) күләме күрсәткечләре саны;

$F_{ij}$ – дәүләт хезмәте күрсәтү (эше) күләме күрсәткеченең факттагы мәгънәсе;

$NF_{ij}$ – дәүләт хезмәте күрсәтүне (эш башкаруны) финанслау нормативы;

$N_{ij}$ – дәүләт йөкләмәсендә күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтү (эшләр башкару) күләме күрсәткеченең башлангыч мәгънәсе.»;

2.1 нче пунктның 2.1.3 нче пунктчасы үз көчен югалткан дип санарга;

2.1 нче пунктның 2.1.4 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.4. «Дәүләт йөкләмәсе составында билгеләнгән күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфаты күрсәткечләренең план мәгънәләренә ирешү» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E = \frac{\sum_{i=1}^{n}\sum_{j=1}^{m} N_{ij} \times \frac{F_{ij}}{P_{ij}}}{\sum_{i=1}^{n} N_{ij}} \times 100\%,$$

монда:

E – дәүләт йөкләмәсе составында билгеләнгән күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты күрсәткечләренең план мәгънәләренә ирешү;

$N_{ij}$ – авырлык коэффициентлары;

$F_{ij}$ – дәүләт йөкләмәсе буенча сыйфатның факттагы күрсәткечләре;

$P_{ij}$ – дәүләт йөкләмәсе буенча сыйфатның план күрсәткечләре;

i – дәүләт хезмәте күрсәтү (эше) номеры;

n – дәүләт хезмәтләре күрсәтү (эшләре) саны;

j – дәүләт хезмәте күрсәтү (эше) сыйфаты күрсәткече;

m – дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре саны.

Күрсәткеч мәгънәсенең уңай динамикасы аның кимүе белән билгеләнсә, түбәндәге формула файдаланыла:

$$E = \frac{\sum_{i=1}^{n}\sum_{j=1}^{m} N_{ij} \times \frac{P_{ij}}{F_{ij}}}{\sum_{i=1}^{n} N_{ij}} \times 100\% .»;$$

2.2 нче пунктның 2.2.1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.1. «Дәүләт йөкләмәсен финанслау күләменә карата керем китерә торган

эшчәнлектән керемнәр күләме мөнәсәбәте» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E = \frac{V_{pdd}}{V_{gz}} \times 100\%,$$

монда:

E - дәүләт йөкләмәсен финанслау күләменә карата керем китерә торган эшчәнлектән керемнәр күләме мөнәсәбәте күрсәткече, процент;

$V_{pdd}$ – керем китерә торган эшчәнлектән дәүләт оешмасы керемнәре күләме, билгеләнгән дәүләт йөкләмәсе чикләрендә түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән) алынган акчадан тыш, сум;

$V_{gz}$ – дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү күләме, сум.»;

2.2 нче пунктның 2.2.2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.2. «Татарстан Республикасында уртача эш хакына карата дәүләт оешмасы хезмәткәрләренең уртача эш хакы мөнәсәбәте» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E = \frac{S_{pers}}{S_{ecom}} \times 100\%,$$

монда:

E – Татарстан Республикасында уртача эш хакына карата дәүләт оешмасы хезмәткәрләренең уртача эш хакы мөнәсәбәте күрсәткече, процент;

Spers – дәүләт оешмасы хезмәткәрләренең уртача эш хакы, сум;

Secom – Татарстан Республикасында уртача эш хакы, сум.»;

2.2 нче пунктның 2.2.3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.3. «Татарстан Республикасы икътисадының тиешле өлкәсендә эшләүче дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең уртача эш хакына карата дәүләт оешмасы хезмәткәрләренең төп төркемнәре буенча уртача эш хакы мөнәсәбәте» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E_i = \frac{S_{pers_i}}{S_{ecom_i}} \times 100\%,$$

монда:

$E_i$ - Татарстан Республикасы икътисадының тиешле өлкәсендә эшләүче дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең уртача эш хакына карата дәүләт оешмасы хезмәткәрләре төп төркеменең уртача эш хакы мөнәсәбәте күрсәткече, процент;

$Spers_i$ – дәүләт оешмасының төп хезмәткәрләре төркеменең уртача эш хакы, сум;

$Secom_i$ – Татарстан Республикасы икътисадының тиешле өлкәсендә эшләүче i-төркеме хезмәткәрләренең уртача эш хакы, сум;

i – хезмәткәрләр төркеме (эшчәнлек өлкәсенә бәйле булган: укытучылар, өлкән һәм урта медицина персоналы, социаль хезмәткәрләр, китапханәчеләр,

артистлар персоналы, тренерлар (тренер-укытучылар), музейлар һәм клуб-буш вакытны уздыру учреждениеләре төп персоналы).»;

2.2 нче пунктның 2.2.4 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.4. «Үткән елның шундый ук чорына карата дәүләт оешмасының дебиторлык бурычлары үзгәрү» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E_i = D_i – D_j’$$

монда:

Ei – дәүләт оешмасының дебиторлык бурычлары үзгәрү, сум;

Di – хисап чоры өчен дебиторлык бурычлары күләме;

Dj – үткән елның шундый ук чоры өчен дебиторлык бурычлары күләме.»;

2.2 нче пунктның 2.2.5 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.5. «Үткән елның шундый ук чорына карата дәүләт оешмасының кредиторлык бурычлары үзгәрү» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E_i = K_i – K_j,$$

монда:

Ei – дәүләт оешмасының дебиторлык бурычлары үзгәрү, сум;

Ki – хисап чоры өчен дебиторлык бурычлары күләме;

Kj – үткән елның шундый ук чоры өчен дебиторлык бурычлары күләме.»;

2.2 нче пунктның 2.2.7 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.7. «Норматив кыйммәткә карата дәүләт оешмасы мөлкәтенең 1 кв.метрын карап тотуның факттагы кыйммәте мөнәсәбәте» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E = \frac{V_{nsi}}{\sum_{i=1}^{n} BNSI_i \times K_{bnsii} \times S_{q_i} \times 12} \times 100\%,$$

монда:

$E$ – норматив кыйммәткә карата дәүләт оешмасы мөлкәтенең 1 кв.метрын карап тотуның факттагы кыйммәте мөнәсәбәте күрсәткече, процент;

$V_{nsi}$ – дәүләт оешмасы мөлкәтен карап тотуга факттагы чыгымнар (коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә, биналарга һәм корылмаларга агымдагы һәм капиталь ремонтка, җиһазларга агымдагы ремонтка һәм аларны сатып алуга, салымнарга, ведомствога карамаган сак хезмәтенә түләү), сум;

$BNSI_i$ – дәүләт оешмасы мөлкәтен карап тоту буенча база нормативы, сум;

$K_{bnsii}$ – дәүләт оешмасы мөлкәтен карап тоту буенча база нормативына карата төзәтү коэффициенты;

$S_{q_i}$ – биналарның һәм корылмаларның ягып җылытыла торган мәйданы, кв.метр;

i – дәүләт хезмәте күрсәтү номеры;

n – дәүләт хезмәтләре күрсәтү (эшләре) саны.»;

2.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Мәгариф өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары.»;

2.3 нче пунктның 2.3.1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.1. «Педагогик һәм башка персоналның (административ-идарә итү, уку-укыту-ярдәмче, хезмәт күрсәтүче кече персонал, шулай ук уку-укыту процессын гамәлгә ашырмаучы педагог хезмәткәрләр) саны мөнәсәбәте» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E = \frac{P_{ped}}{P_{ov}} \times 100\%,$$

монда:

E - педагогик һәм башка персоналның (административ-идарә итү, уку-укыту-ярдәмче, хезмәт күрсәтүче кече персонал, шулай ук уку-укыту процессын гамәлгә ашырмаучы педагог хезмәткәрләр) саны мөнәсәбәте, процент;

$P_{ped}$ – дәүләт оешмасының педагогик персоналы саны, кеше;

$P_{ov}$ - административ-идарә итү, уку-укыту-ярдәмче, хезмәт күрсәтүче кече персонал, шулай ук уку-укыту процессын гамәлгә ашырмаучы педагог хезмәткәрләр саны, кеше.»;

2.3 нче пунктның 2.3.2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.2. «Белем алучыларның гомуми санына карата белем алучылар тарафыннан яки алар катнашында кылынган җинаятьләр саны мөнәсәбәте» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E = \frac{P_i}{M_i} \times 100\%,$$

монда:

E - белем алучыларның гомуми санына карата белем алучылар тарафыннан яки алар катнашында кылынган җинаятьләр саны мөнәсәбәте күрсәткече, процент;

$P_i$ – i-дәүләт оешмасында белем алучылар тарафыннан кылынган җинаятьләр саны, берәмлек;

$M_i$ - i-дәүләт оешмасында белем алучылар саны, кеше.»;

2.4 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

2.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары.»;

2.5 нче пунктның 2.5.1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.1. «Дәүләт оешмасы тарафыннан күрсәтелүче бер хезмәткәргә туры килә торган дәүләт хезмәте күләме» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E_i = \frac{M_i}{F_i},$$

монда:

$E_i$ - i-дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт оешмасының бер хезмәткәренә туры килә торган койка-көннәрнең факттагы саны, койка-көн;

$M_i$ - i-дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт оешмасы хезмәткәрләренең факттагы саны, кеше;

$F_i$ – дәүләт хезмәте күрсәтү күләме күрсәткеченең факттагы мәгънәсе, койка-көн.»;

2.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары.»;

2.6 нчы пунктның 2.6.1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. «Бер хезмәткәргә исәпләгәндә дәүләт оешмасы хезмәт күрсәткән кешеләр (хезмәтләр) саны» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E_i = \frac{M_i}{F_i},$$

монда:

$E_i$ - i-дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт оешмасының бер хезмәткәренә туры килә торган i-дәүләт хезмәте (хезмәтләре) күрсәтүдән файдаланучылар – затлар саны, кеше (хезмәт күрсәтүләр);

$M_i$ - i-дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт оешмасы хезмәткәрләренең факттагы саны, кеше;

$F_i$ – дәүләт хезмәте күрсәтү күләменең факттагы мәгънәсе.»;

2.7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары.»;

2.7 нче пунктның 2.7.2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7.2. «Тренер-укытучылар (тренерлар) саны һәм башка персонал (административ-идарә итү, ярдәмче һәм хезмәт күрсәтүче) саны мөнәсәбәте» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E = \frac{P_{tren}}{P_{ovl}} \times 100\%,$$

монда:

E - тренер-укытучылар (тренерлар) саны һәм башка персонал (административ-идарә итү, ярдәмче һәм хезмәт күрсәтүче) саны мөнәсәбәте, процент;

Ptren – дәүләт физкультура-спорт оешмасының тренер-укытучылары (тренерлары) саны, кеше;

Povl - административ-идарә итү, ярдәмче һәм хезмәт күрсәтүче персонал саны, кеше.»;

2.7 нче пунктның 2.7.3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7.3. «Бер тренер-укытучыга (тренерга) туры килә торган дәүләт физкультура-спорт оешмасында шөгыльләнүчеләр саны» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E_i = \frac{F_i}{M_i},$$

монда:

$E_i$ - i-дәүләт хезмәте күрсәтүче бер тренер-укытучыга (тренерга) туры килә торган i-дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучы затлар саны, кеше;

$F_i$ – дәүләт хезмәте күрсәтү күләменең фактагы мәгънәсе;

$M_i$ - i-дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт физкультура-спорт оешмасы тренер-укытучыларының (тренерларының) фактагы саны.»;

2.8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Яшьләр сәясәте өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары.»;

2.8 нче пунктның 2.8.1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8.1. «Тармак белгечләре саны һәм башка персонал (административ-идарә итү, хезмәт күрсәтүче) саны мөнәсәбәте» критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$E = \frac{P_{otrs}}{P_{pr}} \times 100\%,$$

монда:

E - тармак белгечләре саны һәм башка персонал (административ-идарә итү, хезмәт күрсәтүче) саны мөнәсәбәте, процент;

Potrs – дәүләт оешмасының тармак белгечләре саны, кеше;

Ppr – тармак белгечләреннән тыш, дәүләт оешмасы хезмәткәрләре саны, кеше.»;

3 бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийларының авырлык коэффициентлары»;

1 нче таблицаның 1, 2 нче пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «1. Дәүләт оешмаларының төп эшчәнлеге критерийлары | | | |
| 1.1. | Дәүләт йөкләмәсе күләмен үтәү | 10 | 30 |
| 1.2. | Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәү | 15 | - |
| 1.3. | Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының дәүләт йөкләмәсе составында билгеләнгән план мәгънәләренә ирешү | 15 | - |
| 2. Дәүләт оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге критерийлары | | | |
| 2.1. | Дәүләт йөкләмәсен финанслау күләменә карата керем китерә торган эшчәнлектән алына торган керемнәр күләме мөнәсәбәте | 4 | 10 |
| 2.2. | Татарстан Республикасында уртача айлык эш хакына карата дәүләт оешмасы хезмәткәрләренең уртача эш хакы мөнәсәбәте | 4 | 10 |
| 2.3. | Татарстан Республикасы икътисадының тиешле өлкәсендә эшләүче дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең уртача эш хакына карата дәүләт оешмасы хезмәткәрләренең төп төркемнәре буенча уртача эш хакы мөнәсәбәте | 4 | 8 |
| 2.4. | Үткән елның шундый ук чорына карата дәүләт оешмасының дебиторлык бурычлары үзгәрү | 4 | 6 |
| 2.5. | Үткән елның шундый ук чорына карата дәүләт оешмасының кредиторлык бурычлары үзгәрү | 4 | 6 |
| 2.6. | Уртача норматив кыйммәткә карата дәүләт хезмәте күрсәтүнең уртача факттагы кыйммәте мөнәсәбәте | 5* | 5* |
| 2.7. | Норматив кыйммәткә карата дәүләт оешмасы мөлкәтенең 1 кв.метрын карап тотуның факттагы кыйммәте мөнәсәбәте ** | 5 | 5»; |

1 нче таблицаның 3 нче пункты исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Мәгариф өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары»;

1 нче таблицаның 3.1 нче пунктчасындагы «чагыштырмасы» сүзен «мөнәсәбәте» сүзенә алыштырырга;

1 нче таблицаның 4 нче пункты үз көчен югалткан дип санарга;

1 нче таблицаның 5 нче пункты исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары»;

1 нче таблицаның 5.1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5.1. | Бер хезмәткәргә туры килә торган дәүләт оешмасы тарафыннан күрсәтелүче дәүләт хезмәте күләме | 10 | -»; |

1 нче таблицаның 6 нчы пункты исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары»;

таблицаның 6.1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6.1. | Бер хезмәткәргә исәпләгәндә дәүләт оешмасы тарафыннан хезмәт күрсәтелгән кешеләр (хезмәт күрсәтүләр) саны | 5 | -»; |

1 нче таблицаның 7 нче пункты исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары»;

1 нче таблицаның 7.2 нче пунктчасындагы «чагыштырмасы» сүзен «мөнәсәбәте» сүзенә алыштырырга;

1 нче таблицаның 7.3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «7.3. | Дәүләт физик культура һәм спорт оешмасында шөгыльләнүчеләрнең бер тренер-укытучыга (тренерга) туры килә торган саны | 5 | -»; |

1 нче таблицаның 8 нче пункты исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Яшьләр сәясәте өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмаларының тармак эшчәнлеге критерийлары»;

1 нче таблицаның 8.1 нче пунктчасындагы «чагыштырмасы» сүзен «мөнәсәбәте» сүзенә алыштырырга;

1 нче таблица сылтамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Сәламәтлек саклау өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмалары өчен авырлык коэффициенты мәгънәсе 10 га тигез итеп кабул ителә.

** Сәламәтлек саклау өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче оешмалардан тыш.»;

әлеге карар белән расланган Автоном учреждениеләр икътисадый эшчәнлеге аудитының бертип методикасында:

текст буенча тиешле килешләрдәге «дәүләт учреждениеләре» сүзләрен тиешле килешләрдәге «дәүләт оешмалары» сүзләренә алыштырырга;

1 бүлекнең 1.2 нче пунктындагы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләренә алыштырырга;

1 бүлекнең 1.4 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Учреждениеләр эшчәнлеген бәяләү индикаторлары итеп Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийлары (алга таба – дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийлары) файдаланыла. Дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийларын хисаплап чыгару алгоритмнары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган Мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийларын хисаплап чыгару методикасында (алга таба – Дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийларын хисаплап чыгару методикасы) китерелә.

Күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатын бәяләү критерийлары итеп, дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартлары файдаланыла.

Учреждениеләр эшчәнлеген бәяләү индикаторларының иң чик мәгънәләре итеп Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (алга таба – эшчәнлекне бәяләү критерийларының министрлыклар раслаган мәгънәләре) тарафыннан чираттагы финанс елына һәр дәүләт оешмасы буенча раслана торган дәүләт оешмалары эшчәнлеген бәяләү критерийлары мәгънәләре файдаланыла.»;

4 бүлекнең дүртенче абзацындагы «яки Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре территориаль программасы» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\94.docx